***«ТАНЕКО» ААҖ өчен эчүгә яраклы суга тарифның билгеләнүе турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 07 декабрь 2011 416-ФЗ №лы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге дәүләт тарифларның көйләнүе турында» 13 май 2013 406№лы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Әлеге карарның кушымтасы буенча суык су тәэмин итүче һәм су бүлүне тәэмин итүче «ТАНЕКО» ААҖ өчен эчүгә яраклы суга тарифны билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тариф карарның гамәлгә кергән көненнән башлап 31 декабрь 2013 елга хәтле гамәлдә булачак.
3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 январь 2013 6 №лы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге мәгълүматны ачу стандартлары буенча көйләнүнең чираттагы периодка тарифларның билгеләнүе турында карарның алынган көненнән башлап 30 календарь көненә хәтле «ТАНЕКО» ААҖга мәгълүматны ачырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән ун көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе вазифасын башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 01 ноябрь 2013
10-37/кс №лы карарының
Кушымтасы

Суык су тәэмин итүче һәм су бүлүне тәэмин итүче «ТАНЕКО» ААҖ өчен
эчүгә яраклы суга тариф

(НДС керми)

| № п/п | Муниципаль оешманың, суык су тәэмин итүче һәм су бүлүне тәэмин итүче оешманың исеме | Эчүгә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | |
| 1 | ОАО «ТАНЕКО» | 81,45 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге